ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.09.2024 Олы Кайбыч ав. № 332

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милкендәге, өченче затлар (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга ярдәм итү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 июлендәге 311 номерлы;

«Муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 30 апрелендәге 227 номерлы;

«Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 30 апрелендәге 227 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 15 февралендәге 61 номерлы;

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милкендәге арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне сатып алуга кече һәм урта эшкуарлык субъектларының өстенлекле хокукларын гамәлгә ашырганда сатып алына торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп тору срогын билгеләү турында» 2023 елның 19 октябрендәге 453 номерлы.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштырырга һәм http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе О.Д.Макаровага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров